**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлегенең Татар Мөшегесе торак пунктында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**23.11.2020ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Татар Мөшегесе торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 һәм 2 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Татар Мөшегесе торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен түләү);

2) Татар Мөшегесе торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (койма төзекләндерү, кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Татар Мөшегесе торак пунктында юлларны карап тоту (грейдлау, юлларны чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

4) Татар Мөшегесе торак пунктында су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга мөмкин. (https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы Р.Ш. Газизҗанов